**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422742 Республика Татарстан Атнинский район с. Кулле-Кими ул.Кирова 1А Тел. 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноябрь 2022 ел. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында гражданнарнын узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле узидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2022 елнын 14 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында узара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Яңа Бәрәскә торак пунктында узара салым керту мәсьәләсе буенча халык жыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар жыенын уткәрү вакыты 14 ноябрь 2022ел 11:00 сәг.тан 12:00 сәг.кадәр;
- уткәру урыны — Яңа Бәрәскә авылы, Совет урамы, 16 йорты ;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 2 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитетында гражданнар жыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга тубәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;
- сайлау хокукына ия булган Яңа Бәрәскә торак пунктында яшәучеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар жыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Яңа Бәрәскә торак пункты халкына массакүләм мәгълумәт чараларында гражданнар жыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Кулле-Киме авыл җирлеге Бахтачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Яңа Бәрәскә юлын ремонтлау, вак таш сатып алу һәм салу
- территорияне кардан чистарту
- су системасын ремонтлау
- урам утларына хезмәт күрсәтү һәм яктырткычлар сатып алу

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумәт рәсми порталында тубәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумәт-телекоммуникация челтәрендә тубәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Яңа Бәрәскә авылы, Совет ур.16 йортлардагы мәгълумәт стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар, ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5.Әлеге карарның утәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Х.Х.Гәрәев